| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СТАРОЧЕЛНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ЧАЛЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Иске Чаллы ав. **КАРАР**

**№ 8** **«08» июнь 2026 ел**

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Чаллы авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү турында «Нигезләмә хакында» 2022 елның 20 гыйнварындагы 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Иминият пенсияләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 400-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү турында Нигезләмә хакында» 2022 елның 20 гыйнварындагы 1 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 12нче кушымтаның 2 пунктындагы 2 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Тиешле еллар эшләгән өчен дәүләт яисә муниципаль пенсиягә чыгу дигәндә, картлык буенча иминият пенсиясен алу хокукын бирә торган яшькә җиткәч, муниципаль хезмәттән азат ителү яки «Иминият пенсияләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 400-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, вазыйфада булуның иң чик яшенә җиткәч, инвалидлык буенча иминият пенсиясен билгеләү аңлашыла, эштән азат ителүдән тыш муниципаль хезмәткәрнең гаепле гамәлләренә бәйле рәвештә һәм тиешле еллар эшләгән өчен дәүләт яисә муниципаль пенсия алу өчен кирәкле муниципаль хезмәт стажы булганда.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында https://pravo.tatarstan.ru / һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Иске Чаллы авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Т.В.Савинова